СОВЕТ
БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 27 ноябре Олы Ачасыр авылы № 201

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 01 ноябрендәге 218 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 14 номерлы, 2023 елның 05 октябрендәге 154 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон (2024 елның 29 октябрендәге редакциядә), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында»гы 2019 елның 01 ноябрендәге 218 номерлы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 14 номерлы, 2023 елның 05 октябрендәге 154 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3%, эшкуарлык эшчәнлегендә

файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләрен төшереп калдыру, һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләрен;»;

1.2. 1.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару турында Россия Федерациясенең аерым закон актлары» гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3%, әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләрен;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы урынбасары, Совет рәисе И.М. Саттаров